**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об установлении карантина на территории села Люга Кукморского района Республики Татарстан в связи с ее неблагополучием по заболеванию животных сибирской язвой

В связи с выявлением заболевания животных сибирской язвой и угрозой его распространения в населенных пунктах Республики Татарстан, в соответствии со статьями $3^1$, 17 Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии» **постановляю**:

1. Установить карантин в связи с неблагополучием по заболеванию животных сибирской язвой на территории села Люга Кукморского района Республики Татарстан.

2. На территории, указанной в пункте 1 настоящего Указа, в период действия карантина запрещаются:

ввод и ввоз, вывод и вывоз за пределы карантинированной территории животных всех видов;

заготовка и вывоз продуктов и сырья животного происхождения, перегруппировка (перевод) животных внутри карантинированной территории;

использование молока от больных животных;

убой животных на мясо;

вскрытие трупов и снятие шкур с павших животных;

проведение ветеринарных хирургических операций, кроме неотложных;

вход на неблагополучную территорию посторонним лицам, въезд на ее территорию транспорта, не связанного с обслуживанием данной территории;

выгон животных на водопой из прудов и других естественных водоемов.

3. Установить, что карантин подлежит отмене по истечении 15 дней со дня последнего случая падежа или выздоровления животных при условии выполнения необходимых мероприятий.

4. Главному управлению ветеринарии Кабинета Министров Республики Татарстан разработать и утвердить план мероприятий по ликвидации заболевания животных сибирской язвой на территории,

указанной в пункте 1 настоящего Указа, а также обеспечить его реализацию.

5. Контроль за исполнением настоящего Указа возложить на Кабинет Министров Республики Татарстан.

6. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань,Кремль
07 августа 2014 года
№ УП-760

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Кукмара районының Өлге авылы территориясендә терлекләр түләмә белән авырганга күрә аның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында

Терлекләрнең түләмә белән авыруы ачыклану һәм аның Татарстан Республикасы торак пунктларында таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Кукмара районының Өлге авылы территориясендә терлекләр түләмә белән авырганга күрә аның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертергә.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территориядә карантин гамәле дәвам иткән вакытта түбәндәгеләр тыела:

бөтен төр хайваннарны карантин урнаштырылган территория чикләреннән алып керү һәм алып чыгу, транспортта алып керү һәм алып чыгу;

терлекләрдән продуктлар һәм чимал җитештерү һәм аларны читкә чыгару, хайваннарны карантин урнаштырылган территория эчендә яңадан төркемнәргә аеру (күчерү);

авыру хайваннарның сөтен куллану;

хайваннарны иткә сую;

үләксәләрне яру һәм тиресен тунау;

ашыгыч операцияләрдән тыш, ветеринария хирургия операцияләре уздыру;

иминлексез территориягә чит кешеләрне кертү, әлеге территориягә аңа хезмәт күрсәтү белән бәйле булмаган транспортны кертү;

хайваннарны буаларга һәм башка табигый сулыкларга сугару өчен чыгару.

3. Карантин, зарури чаралар күрү шарты үтәлгәндә, терлекләр үлеменең яисә терелүенең соңгы очрагыннан 15 көн узганнан соң бетерелергә тиеш, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территориядә терлекләрнең түләмә белән авыруын бетерү буенча чаралар планын эшләргә һәм расларга, шулай ук аның гамәлгә ашырылуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2014 ел, 07 август
№ ПУ-760